ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

БУА
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

БУИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ

КАРАР
РЕШЕНИЕ

31 июль 2012ел № 11-21

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен күп балалы гаиләләргә муниципаль милектә булган җирләрдән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлекләре бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»

Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 29 маендагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Буа район Советы карар кабул итте:

1. Буа район Советының 2012 елның 16 мартындагы 10-17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелекалып бару өчен күп балалы гаиләләргә муниципаль милектә булган җирләрдән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлекләре бирү тәртибе турында нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Нигезләмәнең 2.6 нчы пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. ТР Буа муниципаль районы составына керүче шәһәр яки авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче җир кишәрлекләре бирүдә кызыксынучы гражданнарга җир кишәрлекләре тиешле шәһәр яки авыл җирлеге чикләрендә, ә күрсәтелгән гражданнар яшәгән шәһәр яки авыл җирлеге чикләрендә мондый җир кишәрлекләре булмаган очракта, ТР Буа муниципаль районының башка җирлеге чикләрендә бирелә.».

2. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Байрак» район газетасында бастырып чыгарырга һәм ТР Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа район Советы рәисе Р.Х. Абузяров